# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

№ 4 (4)

27 октябрь 2011 ел


## • Ике авыз сүз

24 октябрь көнне ректоратның чираттагы утырышы узды. Көн тәртибенә КФУның Үсеш программасы үтәлү буенча хисап, IT телекоммуникацион структураның торышы, чит ил галимнәрен чакырту һәм университетның күчемсез милкен булдыру буенча экспертлар советларын оештыру, традицион «төрлесеннән» сораулары куелган иде.

Утырышны Илшат Гафуров 2012 елда кабул итү кампаниясенә план әзерләү мәсьәләсеннән башлап җибәрде. Мәктәпләр белән тыгыз элемтә урнаштырырга кирәклеген әйтте.

Үсеш программасының үтәлеше турында икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор М.Сафиуллин сөйләде. Ул чыгышында вузның уңышлары белән беррәттән, кимчелекле якларны да күрсәтте. И.Гафуров артта калучы бүлекләргә ел ахырына кадәр проблемалы күрсәткечләрне тәртипкә китерергә боерды.

Аннан соң КФУның Мәгълүматлаштыру һәм элемтә департаменты җитәкчесе Д.Бурмистров телекоммуникация буенча хезмәт күрсәтүнең торышы турында чыгыш ясады. Ул төп проблемаларны атады һәм аудит үткәрү турында тәкъдим ясады. «Тик аудит мәгълүматлары нигезендә генә максатчан үсеш программасын эшләргә мөмкин булачак», – диде ул. И.Гафуров, Д.Бурмистров сүзләрен тагын да тулыландырып: «Яңа елга кадәр фәнни китапханәдә Wi-Fi кертелгән булырга тиеш. Аның өчен уку корпусларында барлык кирәкле исәпне алырга кирәк», – дип белдерде. Бу мәгълүматлар – декабрьдә, ә үсеш программасы февральаенда тәкъдим ителергә тиеш. И.Гафуров экспертлар советларын оештыруны Д.Нургалиев һәм А.Межвединовка йөкләде. Д.Нургалиев – читтән килгән белгечләр, ә А.Межведилов «Буревестник» һәм «Яльчик» сәламәтләндерү лагерьларын төзекләндерү мәсьәләләре белән шөгыльләнәчәк.

Ректорат әгъзалары Физика институты академигы, университетның кайгыртучанлык советы әгъзасы Ренат Сәгъдиевкә КФУның мактаулы профессоры дигән исем бирү турындагы тәкъдимне бертавыштан хуплады.

И.Гафуров утырышның «төрлесеннән» дигән өлешендә КФУның финанс структурасындагы яңа вазифаларга билгеләнүләр турында сөйләде. Университетта берләштерелгән җәмәгать туклану пунктлары челтәре булдыру һәм уку йортының медицина өлкәсендәге үсеше белән бәйле перспективалы юнәлеше – Республика үзәк хастаханәсенең Укыту-җитештерү үзәге белән хезмәттәшлек итү турында да сөйләде.

• • • •

КФУ составына кергән элеккеге Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты оешуга 135 ел тулды. 1876 елның 24 октябрендә Россиядә өченче булып Казан Укытучылар институтына нигез салына. Күп тапкырлар исемен үзгәрткән уку йорты җисеменә тугры кала. Ул Идел буендагы бик күп башка педагогик вузларның төп нигезе булып тора. 1994 елда университет дәрәҗәсе бирелә, ә 2005 елда аның базасында Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты ачыла. 2011 елның 1 сентябреннән ул КФУга кушылды.

• • • •

25 октябрь университетта РФ Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов булды. Инде 2005 елдан бирле килгән традиция буенча, ул Физика институтының алдынгы студентларына стипендияләр тапшырды. Быел бәхет Ксения Тихонова һәм Рамил Нигъмәтуллинга елмайды.

• • • •

28 октябрь көнне 16 сәгать 30 минутта Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең беренче катында урнашкан конференц-залында «КФУның 10 иң яхшы инновацион идеясе» конкурсының икенче туры үтә. Барлык катнашучылар, студентлар, магистрлар, аспирантлар һәм хезмәткәрләр чакырыла. Финалистларга үз презентацияләрен әзерләп килү шарт.

*ksu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Алия Галимуллина фотосы

# Яшь талантларга бүләк


**Алексей ЛЕОНТЬЕВ,**
«Казан университеты» газетасы хәбәрчесе


Кичә Казан университеты музеенда Е.К.Завойский исемендәге премия тапшыру тантанасы булды. Әлеге премия 1998 елдан бирле физика белгечлеге буенча белем алучы иң талантлы студентларга тапшырыла. Проект Казан мэриясе ярдәме белән тормышка ашырыла.

Быел премия үндүртенче тапкыр тапшырыла. Премиягә кандидатлыкка утызга якын гариза кабул ителгән иде. Шуларның сигезе икенче турга үтте. Чарада КФУ ректоры И.Гафуров, Россия Фәннәр академиясе Казан фәнни үзәгенең физик-техник институты директоры К.Салихов, университетның Физика институты директоры А.Аганов һәм мэрия вәкиле И.Закиров катнашты.

Премия КФУ ассистенты Алексей Заяцка тапшырылды. Икенче урынга Россия Фәннәр академиясе Казан фәнни үзәгенең физик-техник институты вәкиле Камил Кәримуллин лаек булды. Ә өченче урын шул ук фәнни үзәктән Руслан Зариповка бирелде.

## • Таян Аллага – 2011

# Дин һәм иҗат бердәмлеге


**Алмаз МАНСУРОВ,**
татар филологиясе бүлеге студенты


20 октябрь көнне Татарстан Җөмһүрияте Мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан оештырылган «Таян Аллага» икенче әдәби конкурсына нәтиҗәләр ясалды. Шигърият номинациясендә Гран-при КФУның журналистика һәм социология факультетын 2011 елда тәмамлаган Фәнил Гыйләҗевка бирелде.

«Ностальгия» ресторанына килеп керүгә, ишек төбендә җыелган бер төркем яшьләргә игътибар иттем. Тыйнак кына сөйләшеп торучы яулыклы кызлар, түбәтәйле егетләр бу чараның башка әдәби конкурслардан нык кына аерылып торуын искәртәләр сыман. Аңлашылганча, бәйгенең катнашучылары – мөселман яшьләре.


**Ахыры 3нче биттә.**




*Рәсемдә: ТР Диния нәзарәте рәисе Илдус хәзрәт Фәйз Гран-прины Фәнил Гыйләҗевка тапшыра*

# КФУга тагын бер университет өстәлде

КФУда Балалар университеты үз эшен башлап җибәрә. Ул уку йортыбызда эшләүче укытучыларның, галимнәрнең, хезмәткәрләрнең балаларын, оныкларын, белем алучы студентларның эне-сеңелләрен көтеп кала.

30 октябрь көнне сәгать унда УНИКСта уникаль проект – «Балалар университеты»ның презентациясе булачак. Проект җитәкчесе – КФУның Тарих институты профессоры Валерий Алексеевич Летяев.

Шунысын да билгеләп үтик: «университет» ректор Илшат Гафуров ярдәме белән барлыкка килде һәм Казан университетының Үсеш программасына да кертелде. «Балалар университет»ында шулай ук Идел буе федераль округының Көнчыгыш университетлар ассоциациясе мәйданчыгы да булыр дип планлаштырыла.

Бу «университет» 8-12 яшьлек балаларга исәпләнгән. Проект аларны кызыксындыра торган фәнни юнәлештәге сорауларны ачыклауга юнәлдерелә. «Кешеләр нигә очмый?», «Йолдызлар кая атыла?», «Акчаны кем уйлап тапкан?» һ.б. шундый типик сораулар алар, тик җавап бирүләре генә бик җиңел түгел, шулай бит?

«Балалар университеты»на алдан ук 236-79-80 телефонына шалтыратып язылырга мөмкин. Проектта катнашу түләүсез.

***30 октябрь көнне үтәчәк презентациянең программасы:***

**9.00-10.00** – Теркәлү. Теркәлү үткәндә, балага «студент билеты» һәм «студент кейсы» тапшыралачак.

**10.00-10.30** – «Балалар университеты»н презентацияләү.

**10.45-11.25** – Беренче лекция. Темасы: «Ни өчен студентларны докторлар «укыта»? Кемнәр алар студентлар һәм ни өчен университетка йөриләр?»

***Киләсе айларда үтәчәк лекцияләр тәртибе:***

**31 октябрь:** «Билетларны нигә сатып алалар?» (Гражданлык хокукы) һәм «Казан Кремлен кем һәм ни өчен төзегән?» (Тарих һәм археология).

**13 ноябрь:** «Кемнәр алар немецлар?» (Немец филологиясе һәм немец халкы мәдәнияте) һәм «Минем нинди хокукларым бар һәм мине кем яклар?» (Хокук).

**20 ноябрь:** «Ни өчен уен бик мөһим чара?» (Психология) һәм «Ничек дуслашырга?» (Психология).

Аннан алдагы дәресләр айга бер мәртәбә якшәмбе көнне (10.00-11.15) булачак. Сезне Балалар университетында күңелле аралашулар көтә! Рәхим итегез!



# Барлык уңайлыклар – студентларга!

**Матбугат үзәге**





25 октябрь көнне КФУның Филология һәм сәнгать институтында Sanako фирмасының лингофон кабинетларын программалаштыру һәм җиһазлау буенча презентация узды.

Очрашуда Polymedia компаниясе вәкилләре һәм КФУ ректоры Илшат Гафуров, Филология һәм сәнгать институты директоры Рәдиф Җамалетдинов, тышкы элемтәләр буенча проректор Линар Латыйпов булдылар.

Илшат Гафуров сүзләренчә, вузларны лингофон кабинетлары белән җиһазлау һәм аларны укыту процессында актив куллану белем бирү сыйфатын тагын да күтәрәчәк. «Бигрәк тә бу булачак тәрҗемәчеләр һәм лингвистларны әзерләүдә бик мөһим», – дип билгеләп үтте Р.Җамалетдинов.

Polymedia компаниясе вузга ике төрле материал тәкъдим итте. Алар – Lab 300 һәм Study 1200. Уку йорты вәкилләре әйтүенчә, аларның һәркайсы үзенчә уникаль.

Мәсәлән, телләрне өйрәнүдә Lab 300 үзенең аудио-сигналларны югары сыйфатлы итеп җибәрә алуы белән алдырса, Stady 1200 – беренче вариантның төп сыйфатларының гадиләштерелгән моделе.

Техник һәм башка сыйфатлар турында фикер алышкач, беренче этапта Казан федераль университеты җитәкчелеге бу юнәлештә 15 комплект алырга дигән карарга килде. Эштә сынап караганнан соң, әгәр дә уңышлы булса, продукцияне тулаем университет өчен дә сатып алырга мөмкин булачак. «Без элек тә бу фирма белән эш итә идек. Мультимедия аппаратын алардан алдык, тик аның өчен бу дәрәҗәдәге техник җиһазлау юк иде», – дип фикерләре белән уртаклашты Рәдиф Җамалетдинов.

● Фән дөньясында

# Конфликтологлар да, медиатрлар да...

**Виктория ШУБЕЙКИНА,**
конфликтология бүлеге студенты

21 октябрь көнне фәлсәфә факультетында «Конфликтларны өйрәнү методологиясе» дип аталган Бөтенроссия семинары узды. Бирелдә конфликтларны өйрәнү мәсьәләләренә кагылган төрле сорауларга җавап табылды.

Кешеләрне Борынгы Греция заманнарыннан ук конфликтлар кызыксындырган. Бөек акыл ияләренең һәм аларның шәкертләренең конфликтларга кагылышлы төрле фикерләре, уйлары булган. Барлык кешелек эволюциясе дәвамында низаглanuчы яклар турындагы сорау актуаль булып кала биргән. Тик XX гасыр уртасында гына, социология һәм психология фәннәреннән аерылып чыгу юлы белән, конфликтлар турында аерым фән – конфликтология туа. Ул Европа һәм Америка тәҗрибәсендә күптән никлап тикшерелгән һәм актив кулланылыш кергән. Россия фән дөньясында яңа юнәлеш буларак әле кереп килгән конфликтология зур өметләр уята. 2009 елны беренче мәртәбә Казан (Идел буе) университетында бу белгечлеккә кабул итү башлана. Бүлекнең максаты – гамәли яктан сыйфатлы итеп конфликтларны чишә алырлык белгечләр әзерләү.

Монда алдан ук гамәли нигез әзерләнә. Россия Федерациясендә 2011 елның 1 гыйнвареннан медиация турындагы закон үз көченә керде. Югары классллы укытучыларыбыз ел саен үз белемнәрен тирәнәйтеп һәм камилләштереп торалар. Алар безгә, булачак конфликтологларга, психология, социология, төрле дәрәҗәдәге политология, икътисад, юриспруденция, менеджмент, бизнес һ.б. өлкәләрдә дә гыйлемле булырга мөмкинлекләр ача. Алда аталган Федераль закон РФ альтернатив процедураларында бәхәсләрне, конфликтларны хәл итүче сыйфатында катнашкан мөстәкыйль шәхес – медиатрларга хокукый шартлар булдыру максатыннан эшләнгән. Конфликтология бүлегенең укытучылар коллективы бу яңалыкны тиз тотып алды һәм КФУда медиация үзәген булдыру өчен әзерлекне башлап җибәрде. Инде аны ачу тантанасын көтәбез. Бу үзәктә без – студентлар гамәли яктан бик зур тәҗрибә туплаячакбыз. Медиация буенча өстәмә белем алган галимнәр, укытучылар, безнең һөнәри осталыкны үстерү өчен, бар тырышлыкларын куеп эшлиләр.



■ *«Тынычлык көне» мизгелләре*

Бүлекнең үз традицияләре дә барлыкка килде. Мәсәлән, «Тынычлык көне» дип аталган конфликтологлар бәйрәме әнә шундыйлардан.

Бу бүлектә ике ел уку дәверендә, шуны аңладым: илебез, җәмгыятебез даими рәвештә тынычлыкка мохтаҗ. Шулай булгач, конфликтологларга эш җитәрлек әле.

● Ерактагы якын кардәшләр

# Халкың белән «Элемтәдә»

**Лилия ГАЙНАНОВА,**
Санкт-Петербург шәһәре

Минем Санкт-Петербург татар диаспорасы белән танышу ике ел элек башланып китте. Интернетта кирәкле мәгълүмат эзләп утырган чакта, бер кызыклы elemtede.ru сайтына тап булдым. Нева елгасы буенда урнашкан шәһәрдә «Элемтәдә» яшьләр ассоциациясе бик актив эшчәнлек алып бара икән. Алар уздыра торган иҗади чаралар – очрашулар, театр, музей һәм күргәзмәләргә, әдәби кичәләргә йөрүләр мине таң калдырды. «Элемтәдә» ассоциациясенең эшчәнлеге шуннан башланса, Санкт-Петербург татарлары тарихы бик еракка барып тоташа...

Әлеге шәһәрдә татарлар аның беренче көннәреннән үк яши башлый. Алар Империянең яңа башкаласын төзергә башка халыклар белән бергә килә. Ләкин озакламый татарлар гомуми халык массасыннан аерылып чыга башлый. XVI гасырдан алып, Казан ханлыгы Россия дәүләте составына кергәннән соң, биредә яшәүчеләр арасында татарлар белемле, алга киткән халыклардан саналган. Санкт-Петербургка кара эшче булып килгән татарлар озакламый төрле трактир, ресторан һәм сәнәгать оешмаларының җитәкчеләре булып китәләр.



■ Рәсемдә «Элемтәдә» ассоциация вәкилләре

*Безнең: «Тел бетә, милләт бетә», – дип елап ятырга вакыт юк. Булганны сакларга, булмаганны булдырырга тырышабыз. Икенче башкалабыз Санкт-Петербургка килегез һәм, безнең уңышларны күреп, үзегез дә сөенерсез!*

Шулай итеп, 2003 елда нәкъ 300 еллык тарихы булган шәһәрдә актив татар яшьләре үз эшчәнлекләрен башлап җибәрә. Евгений Хәмидов сөйләгәнчә: «Бернәрсә дә җиңел генә бирелми. Безнең юлда да төрле кыенлыклар очрады, ләкин югалып калмадык. Үзебез кебек актив якташларны, дусларны таптык. Бу эшне башлап җибәрергә безгә Ислам Фонды каршында ачылган татар теле курслары ярдәм итте. Аны Әлмәт шәһәреннән килгән бик яхшы педагог Альбина Ишмурзина җитәкли. Әле танылу алмаган курсларга беренче укучыларын җәлеп итү җиңел булмады. Мегаполиста да татар теленең кирәклеген аңлаган кешеләр табылды. Шунсы игътибарга лаек: әлеге курслар төрле яшьтәге милләттәшләрне берләштерә. Хәтта бабалары татар булып, бүген урыслашып баручылар да бирегә бик теләп йөри. Татарстан мәктәпләрен тәмамлап, югары белем алырга килгән студентлар, бер-берсен эзләп табып, шунда җыела. Төркемнәр, берләшеп, ял көннәрендә беренче чараларны да оештыра».

Курсларда татар теле дәресләре белән генә чикләнеп калмыйлар, ә гореф-гадәтләребезне, йолаларны, халык җырларын һәм биюләрен өйрәнәләр. Нәтиҗәдә, оешкан төркем шәһәр күләмендәге татар бәйрәмнәренең төп кунакларына әверелә. Үз программаларын булдырган яшьләрнең чыгышлары барлык тамашачыны таң калдыра. «Яшь йөрәкләр» ансамблен һәрвакыт көчле алкышларга күмәләр.

Шул рәвешле, 2007 елда барлык татарларны берләштереп тора торган «Элемтәдә» яшьләр ассоциациясе барлыкка килә. Бөтен татарларны мәгълүматлаштырып, берләштереп тора ул. Спортка булган мәхәббәт команданы тагын да берләштерә. Күпсанлы иҗади, дини, агарту чараларыннан тыш, өстәл теннисы һәм футбол буенча чемпионатлар уздырыла. Даими рәвештә «Тамга» электрон газетасы чыга. Ул башка өлкәләрдә яшәүче милләттәшләр, татар оешмалары белән элемтә урнаштырырга ярдәм итә.

● Таян Аллага – 2011

# Дин һәм иҗат бердәмлеге

Башы 1нче биттә.

Чараның ресторанда уздырылуы да матур күренеш. Ресторан дигәч, без, гадәттә, зыялы, затлы кешеләр йөри торган урынны күз алдына китерәбез. Ә бу көнне «Таян Аллага» бәйгесенә нәтиҗәләр ясар өчен, күренекле галимнәр, танылган шагыйрь-язучылар килгән иде. Алар арасында шагыйрьләр Разил Вәлиев, Равил Фәйзуллин, язучылар Мөсәгыйть Хәбибуллин, Вакыйф Нуриев, Рәфкать Кәрами, галимнәребез Фоат Галимуллин, Фәридә Хәсәнова, Әлфәт Закирҗанов һ.б. булды.

Бәйрәмне үзенең вәгазе белән ТР Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәйз ачып җибәрде. «Һәр кеше Аллаһка таянып яши, – диде ул үзенең чыгышында. – Безгә рәхәт булганда, Аны искә алмасак та, ахыр чиктә, теш сызласа, авырып китсәк яки соңгы сулышыбызда без барыбер Аллаһка мөрәҗәгать итәбез». Шушы сүзләргә нигезләнеп, Илдус хәзрәт безне тарихка күз салырга чакырды. Борынгы шагыйрьләребез Ясәви, Котби, Каргалый иҗатларына карасак та, Габдулла Тукай иҗатына игътибарны юнәлтсәк тә, алардагы дини тематиканы күзәтә алабыз. Гомер-гомергә иҗат белән дин янәшә атлаган. Мөфти сүзләре белән әйтсәк: «Шәхес Аллаһы Тәгаләдән килә. Милли тәрбия, дин, милли хисләр, иҗат бербөтен. Шуның нигезендә әхлакый, тәрбияви әсәрләр туа да инде».



Бәйге өч этапта үтте: әсәрләрне җыю, бәяләү һәм нәтиҗәләр ясау. Жюри әгъзалары филология фәннәре докторы Фоат Галимуллин, филология фәннәре кандидатлары Фәридә Хәсәнова һәм Рамил Ханнанов бер язманы да игътибарсыз калдырмадылар. Конкурска төрле жанрдагы әсәрләр кабул ителде. Алар арасында күләмле повесть та, драма әсәрләре дә, шигырьләр, хикәяләр дә бар.

«Таян Аллага» Икенче әдәби конкурсының жюри әгъзалары түбәндәге фикергә килделәр: татар филологиясе бүлеге студенты Булат Ибраһим (поэзия) белән шул ук бүлекне 2011 елда тәмамлаган Гөлнирә Хөсәенова (проза) беренче урыннарга лаек дип табылды. Шулай ук бүләкләнүчеләр арасында Руфинә Габдрахманова, Алмаз Мансуров, Ядкәр Шәрапов, Айдар Шәйхин да бар иде. Барлык катнашучыларның да әсәрләре җыентыкка тупланып басылып чыкты.

Чара күңелле генә барды. Бер яктан катнашучылар сыгылып торган өстәлләрдәге тәм-томнардан авыз итсәләр, икенче яктан үзләренә җан азыгы алдылар. Җиңүчеләр дә, олпат шәхесләребез дә, ялындырып тормыйча, үзләренең фикерләре, иҗат җимешләре белән бүлешергә ашыктылар.

Чарада проблемалар да читләтеп үтелмәде. Мөфти Илдус хәзрәт Фәйз бүгенге көндә әдәби әсәрләрдә дини образлар, аеруча муллалар тиешенчә тасвирланмаганын билгеләп үтте. Аларны XX йөз башындагы кебек надан, иске карашлы, сәдака өчен йөрүчеләр итеп түгел, ә белемле, халык өчен тырышучы кешеләр икәнен ассызыклап тасвирларга кирәклеген җиткерде.

Шулай ук «Таян Аллага» конкурсының киләчәге турында да сүз алып барылды. Вәлиулла хәзрәт Якупов әйтүенчә, бу бәйге дәвамлы булачак. Катлаулы заманда яшьләрне үстерү, динне пропагандалау аеруча мөһим дигән фикер җиткерде ул.

Гадәттә, һәр җиңүчеләре булган бәйгенең җиңелүчеләре дә була. Тик бу сүзләр «Таян Аллага» конкурсына карата әйтелә алмый. Чөнки аның катнашучылары, беренче чиратта, күңел кушуы буенча, Аллаһ ризалыгы өчен иҗат итәләр. Максатлары да киләчәгебезне матурлау, сәламәт җәмгыять тәрбияләү. Иншалла, бу конкурс алдагы елларда да дәвам итәр!

● Алар бездә укыган

# «Армиягә мине 8 кыз озатты… »

**Лилия БӘДРЕТДИНОВА,**
хәбәрче

Марат Закир – шигърият һәм проза жанрларында актив эшләүче урта буын каләм әһелләренең берсе.



*Аның беренче иҗат тәҗрибәләре балалар матбугатында 1983 елдан басыла башлый. Укучыларга хикәяләре, повесть һәм шигырьләре аша билгеле. 2005 елда «Кояшлы төн» исемле беренче китабы дөнья күрә. 1999 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.*

*Марат Закир (Марат Хәлил улы Закиров) 1969 елның 27 апрелендә Татарстанның Мамадыш районы Дусай авылында туа. 1986 елда Түбән Тәкәнеш урта мәктәбен тәмамлап, КДПИга укырга керә... Аның шуннан соңгы тормыш юлын минем белән корган әңгәмәсеннән укып белә алырсыз.*

*«Мәктәптә укыганда ук языштыргалый башладым мин, – дип башлап җибәрде сүзен Марат абый. – Сыйныфташ егет «Яшь Ленинчы» газетасына шигырь язып җибәргәч, миндә дә кызыксыну уянды. Шигырь яздым да «Ялкын» журналына җибәрдем. Ул вакытта баш мөхәррир Фәез абый Зөлкәрнәй иде. Берникадәр вакыттан соң миңа җавап хаты килде. «Кадерле укучым!» дип кулдан, ә калганын машинкада язган. «Бераз эшлисе, шигырьләреңне төзәтәсе бар, тагын иҗат ит!» дигән. Мин кабат язам, тагын шундый хат килеп төшә, бастырмыйлар. Мин кабат язам... Берсендә Фәез абыйның кулдан бер табак бит тутырып язган хатын алдым. Киңәшләрен биргән. Хәзер генә шуның асылына төшендем. Ул аны, иренмичә, миңа киңәшләрен бирү өчен язып җибәргән бит! Үҗәтлек тә көчле булгандыр инде. «Ялкын» журналы уздырган «Чаткылар» конкурсында җиңеп чыккан идем. Шул көннән соң Казанга китәм, КДПИга укырга керәм, дип йөрдем. Әни: «Керә алмассың син анда, конкурс та зур», – дигәнгә дә карамыйча, имтихан тапшырырга килдем.*

*Менә, ниһаять, без имтихан алучылар каршында! Миңа сорау бирүче кеше – радио дикторы Фоат Галимуллин! Әлеге таныш тавыш иясен үз күзләрем белән күрү миңа, гади авыл баласына, ышаныч иңдерә. Фоат абый белән танышлык шунда башланып китте. Ул әле газета-журналлардан минем язмаларны да укып бара икән!..*

*Мин беренче номерлы тулай торакта, 242нче бүлмәдә тордым. Кайсыдыр бер чибәренә шигырь багышлап, аны бүлмә стенасына язып куйган идем. Обоиларны алыштыра тордылар, әмма минем шигырем һаман да шул үз урынында кала бирде. Бүген анда юктыр инде ул...*

*Күрше бүлмәгә урнашкан Әтнә кызы Миләүшәнең (диктор Миләүшә Насыйбуллина) «Әчкечем кая киткән?» һ.б. гел «ә»ләрдән торган җөмләләрен кызыксынып тыңлап, кызларны кинотеатрларга алып барып, тулай торакка кайта белми адашып, гомумән, бәхетле студент тормышы кичереп йөргән вакытта гына... әни үлеп китте. Ул вакытлар бик авыр булуга карамастан, кеше хәленә керә алырдай группам, һәм, әлбәттә, кураторыбыз Роза апа Асылгәрәева бар иде. Бүгенге көндә дә мин аларга бик рәхмәтле. Берничә айдан армиягә повестка килеп төште. Укуны калдырып, армиягә китеп бардым. Тагын шунысы истә калган: группада бер генә егет булгангадырмы инде, 8 кыз мине армиягә 8 кульяулык чигеп озатты...*

*Армиядән кайткач, яңадан укырга кердем. Ул вакытта «Илһам» әдәби-иҗат түгәрәге тулы көчкә эшләп килә иде. Шул елларда «Шәһри Казан» газетасына эшкә урнаштым. Әлеге газетада әдәби хезмәткәр сыйфатында журналистлык юлын башладым. Уку белән эшне бергә алып бару уңайсыз булгандыр инде, читтән торып уку бүлегенә күчтем.*

*Укуы да укуы, менә тулай торак бик сагындырды. Берсендә шулай бүлмәдә дүртәү яшәп ятканда, тагын берәүне керттеләр. Мөдәррис ага Әгъләмов икән. Ул да кергәч, бүлмәдә бөтенләй диярлек урын калмады, шуңа күрә караватларны ике яруслы итеп ясап куйдык. Күршедәге тулай торакка кереп, вахтер булып эшләгән марҗа хатынын кычкыртулар әле бүгенгәчә хәтердә саклана...*

*1993 елда «Идел» журналына эшкә килдем. Анда сигез ел хезмәт иткәннән соң, 2001 елда «Казан утлары»на урнаштым. Менә бүгенгәчә проза бүлеге мөхәррире булып хезмәт итәм».*

*Беләм, сөйлисе сүзләр, хәтер янчыгында актарылмаган хатирәләр, борчу-шатлыклар бик күптер әле. Әмма сөйләгән кадәресен мин күз дә йоммый тыңлап бардым. Һәр кешенең студент еллары шундый матур хатирәләргә бай, еллар үткәч тә горурланып сөйләрлек Укытучыларыбыз булсын!*

Илһам канатында



Алмаз МАНСУРОВ:
«Мине Казан шәһәрендә 1991 елның хуш исле май аенда тудын, диеп сөйлиләр. Балачагым башкаларныкы кебек үк, агач кашык белән бәрәнге ашап үтте. Хәзерге вакытта югары уку йорты сукмагын таптыйм. Таш арасыннан шыткан яшеллек сыман, йөрәгемдә дә иҗади үсентеләр арта тора. Алар сезнен күнелегездә берәр эз калдырсалар, мин бик шат булыр идем».

# Ә яшәргә кирәк...

Урамга чыгуга, иртәнге салкынлык үз кочагына ала. Аннан арынырга теләп, якаңны күтәреп куясың да тиз-тиз тукталышка атлыйсың.

Йокы килә... Күзләр йомыла. Шуңа күрә дә, башыңны ия төшеп, йокымсырап юл буйлап барасың. Көтмәгәндә, борылыштан машина күренә һәм зәһәр ыжгырып синең өстеңә килә башлый.

Тормозлар чиелдаган тавыштан айнып китәсең.

– Нәрсә?.. Якты дөньяда яшәүләрдән туйдыңмы әллә?

Шофёр җикеренеп кычкыра да сүгенә-сүгенә кузгалып китә! Ә син аның артыннан битараф кына карап каласың. Әле әчтән генә: «Бәлки, үлгән булсам, җиңелрәк тә булыр иде», – диеп уйлап куясың.

Менә тукталыш. Бер кырыйга барып басасың да тирә-ягыңа күз саласың. Кемне хәлең кызыксындырыр икән? Юк, берәү дә синә игътибар итмәс. Чөнки халыкның карашы урам башында. Барысы да зарыгып автобус көтә. Әйтерсең лә, киләчәк бары тик шул кызыл автобуска гына бәйле.



Әнҗе Ибраһимова фотосы

Хәтта иснәнеп, ризык эзләп йөруче урам эте дә әһәмият бирми сиңа. Чөнки ул белә: кесәләрең буш һәм берни дә өмет итеп булмый. Синең дипломлы булуың да, инде ничә ай эш таба алмыйча газапланып йөрүең дә киркәмни аңа.

Күзең акча теләнеп утыручы бер адәмгә төшә. Соңгы елларда «бомж» дигән профессия дә барлыкка килде түгелме? Ә ул үзе бик канәгать. Яңа гына бушаган аракы шешәсен тәгәрәтеп уйнап утыра. Әйе, күңелләр дә шул шешә кебек күптән бушаган икән...

Тукталышка җан керде. Әһә, автобус килә. Шуңа күрә дә кешеләр, бер-берсен этә-этә, алгарак басарга тырышалар. Юкса, утырырга өлгермәсәң, китеп барса...

Син дә урыныңнан кузгалып куясың.

Автобус әкрен генә килеп туктый. Ишекләр ачыла. Кешеләрнең төшүен дә көтмичә, халык әчкә омтыла. Шул агымга буйсынып, син дә түргә узасың.

Буш утыргыч күреп, сабый кебек сөенәсең. Бераз черем итеп алу нияте белән барып утырасың. Күзләрең йомыла... Автобусның салмак тибрәлүенә буйсынып йокыга таласың.

Тик бу халәтең озакка бармый. Киләсе тукталышны игълан иткән тавышка уянып китәсең. Күзләреңне ачасың һәм, янында гына олы яшьтәге кешеләр басып торуын күреп, урыныңнан кузгаласың:

– Рәхим итегез!

Утыргычка бер абзый менеп кунаклый. Соңгы фикерен искә төшерергә теләгәндәй, тәрәзәдән урамга күз сала да иптәшенә сөйләп китә:

– Беләсеңме, миңа инде җитмеш яшь, әле өйдә утырырга җыенмыйм. Бераз эшләгән кыяфәт чыгарып йөрергә исәп бар. Ә нәрсә, акча түлиләр... Үзебез тырышмасак, безне кем кайгыртыр.

– Шулай...

– Ә син яшьләргә кара... Бөтенләй өмет юк бит аларда. Барысы да ялкаулар...

Улузенең сүзләреннән канәгать калып елмая да тынып кала. Ә син оялып куясың. Үзеңнең шундый булдыксызлыгыңнан читенсенәсең. Ничек тә эш табарга кирәк, дигән фикер зиһенеңне көйдереп уза. Тик нишләргә? Сине кечкенәдән олыларны хөрмәт итәргә өйрәтеп үстерделәр түгелме? Димәк, юл бирүдән башка чара юк...

Ә яшәргә кирәк! Ничек? Каршыңа очраган өлкән яшьтәге һәр танышыңа шушы сорауны бирәсең килә – булдыра алмыйсың. Күңелеңнең иң тирән почмагына яшерелгән үпкә хисең кыбырсып куя. Шуңа күрә алар янынннан бары башыңны игән хәлдә, пышылдап кына исәнләшеп узып китәсең.

• Халәт

# Сагыну

**Алсу НУРГАТИНА,**
журналистика һәм социология факультеты студенты

Ят шәһәрдә инде икенче аем узып бара... Сагынуга чик-чама юк. Туган авылымның өрәмәләре, су буйлары, йортыма бара торган тыкрык та күз алдыма килеп баса. Әнием... Көннәр буе миңа изге догасын кылып йөргән, юксынуга түзә алмый, әтиемә күрсәтмичә генә яулык очы белән яшьләрен сөртеп алган газизем минем...

Туган йорттан читкә киткәч, әнием бигрәк тә якын була башлады... Иртә таңнан уянам да, ашарга әзерләп, утырып ашыйм, аннары университетыма юл тотам. Иртән иркәләнеп ятып булмый, барсына да өлгерәсе килә. Әнинең тәмле, бу китереп торган бәлешләре юк шул инде монда. Туган йортта ансын да елап булмый. Монда исә бер чынаяк җылы чәйгә дә күңел сөенә. Төннәрендә кайвакыт өшеп уянып китәм, юрган идәнгә төшкән була. Бу сагынуга тагын бер тамчы өсти. Әнием төсле, таң җиледәй кыты тыршы куллары белән башымнан сыйпап, идәндәге юрганы иңгә кенә өстемә ябучы юк шул монда. Уйларымнан өшеп китәм. Нишлиләр икән өйдә?! Сеңлем, дәрес әзерләп, йокларга яткандыр, әти белән әни телевизор карыйлардыр, абый – компьютерда... Ә мин?! Ә мин, сагынуга бирелеп, карават почмагында тезләремне кочаклап утырам. Сагындым, бик сагындым...

Йолдызлы кичләргә төренгән май ахырларын хәтерлим. Менә имтиханнарны тапшырам да шәһәргә китәм, яңа тормыш, яңа дуслар. Барысы да ал да гөл булыр төсле. Җәй кереп, җылы көннәр тора башлау белән үк, әни кыбырсый башлады: «Тагын урын-җире җыймаган, киемнәрең тузып ята, китап киштәсендәге тузан шул килеш! Син шәһәрдә дә шул булырсың инде, и Ходаем, нишләр бу бала...» Бик үпкәли идем әнигә бу сүзләрдән соң. Аратирә каршы да әйткәли идем. Әнинең һаман үзәге өзелде. Нигә шулай өзгәләнә? Армиягә китмим бит, укырга гына. Эх!.. Хәзер әнинең җылы сүзләрен түгел, әнә шул шелтәләрен тыңлар өчен дә күпне бирер идем. Киштә дә, шкафта тәртиптә. Тузаннар сөртелгән, киемнәр үтүкләп, җыештырып куелган. Әле авылдан бәрәнге тәяп килгән капчыкны да агартып юып куйдым. Заманында шикәр саклагыч хезмәтен үтәгән капчык тәмам каралып беткән иде. Киптердем. Авылга алып кайтырмын. Миңа әни бәрәнге төягән капчык бит ул, туган йорт капчыгы...



Әллә ничек, һаман күнел булмый бу шәһәр тормышына. Нигә, кая ашкындым мин? Менә шулмы минем бар хыялларым, җәй буена түземсезлек белән көткән «яңа» тормыш. Юк, туган авыл белән тиңләп тә булмый. Җәйге җылы кичләре, клубтан ашыкмый гына атлап кайтулар, төнге азанның моңлы агышы. Ә шәһәрдә машиналар тавышы күңелгә тия... Тынычлык юк. Хәлдән килсә, туктатыр идем мин бу ташкынны. Юлларда автобуслар һәм хөкүмәт машиналарын гына калдырыр идем. Җәяү йөрсеннәр! Файдалы да, тыныч та...

Күнел моңсулык диңгезенә чумды. Нигә шулай әрнисоңул?! Әллә көзләр килгәнгә шулай микән?! Табигатьнең шавы йөрәккә кушылган, йөрәк белән бергә тибә. Көз, пыскак яңгырлар ява, инде шәрәләнеп барган агачлар ыңгыраша... Яңгырлары да бит сабый бала күңеле төсле: бер туктап ала да коеп китә, аннары тагын ява башлый... Шәһәр шулай үзеннән куа төсле... Авылда бит, яңгыр яуса да, барыбер җылы була иде. Яңгыр астында кайтасың да кайнар чәй эчеп җылынасың. Әллә әни якын булганга, шулай җылы булды микән? Әни җылысы һәр балага җитә, диләр... Сагындым, авылымның урамнарын, черем ут кабызган фонарь яктыларын сагындым...

Сөгать инде кичке сигез булып килә... Туктале, ник монда балавыз сыгып, борчусагышларымда көзне гаеплән утырам?! Киемнәремне җыям да хәзер үк авылга. Караңгылык пәрдәсен ера-ера, туптуры автовокзалга! Сигездәге автобуска өлгерәм әле...

• Идел кинлекләре

## Чупләмә һәм Сурхури

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче



Бәйрәмнәр халыкның борыңгы һәм хәзерге яшәешен чагылдыра.

Традицион халык мәдәниятендә ял итү, күнел ачу беркайчан да ялкаулык, буш вакыт буларак кабул ителмәгән. Бәйрәмнәр һәрвакыт житди җәмгыять функцияләрен үтәгән һәм бик тирән мәгънәгә ия булган.

Бүген без күрше чуаш халкының көз көне үткәрелә торган йолалары, бәйрәмнәре турында сөйләшәбез.

Көзге көн белән төн тоташкан вакытта (21-22 сентябрь), еллык хуҗалык эшләрен төгәлләп, чуашларда Чүкләмә дигән гаилә-буын бәйрәме уза. Ата-бабаларның рухына багышлап корбан чалдыру ритуалы да шул көнне була. Яңа гына бакыйлыкка күчкәннәрне алданрак вафат булганнар белән берләштерү йоласы (Юпа) да башкарыла. Алар җылы, рәхмәтле изге-җәйге сезоннан салкын көзге-кышкы чорга күчүне билгеләп үтәләр.

Мәҗүсиләр кузаллавы буенча, яз һәм җәй айларында җирдә изгелек, уңдырышлылык көчләре хөкем сөрә, шуңа күрә барлык йолалар да аларны саклап калуга юнәлдерелә. Ә көзге-кышкы чорда, киресенчә, җимергеч көчләр идарә итә. Барлык йолалар да начар көчләрдән һәм куркыныч әйберләрдән арыну өчен башкарыла.

Кышкы көн белән төн тоташкан чор 21-22 декабрьгә туры килә. Бу вакытта чуашлар Сурхури үткәрәләр. Максаты – шулай ук усал җаннарны куу һәм игелекле җәмгыять булдыру. Мәсәлән, бу көнне ряженыйлар (светок, шуйттан ваййи) йорт буенча кереп йөри. Йолада катнашучыларның хәрәкәтләре начар көчләрне куга юнәлдерелә. Ряженыйлар усал җаннарның үлемен тасвирлап күрсәтә.

**Игътибар!**

Сабыйлар өчен әр-яңа «Тылсымлы куллар» журналы дөнья күрде! Мавыктыргыч әкиятләр, сыйфатлы кәгазьдә басыла торган журналны әйтә яздыру мөмкинлеге дә бар! 2011 елның 25 декабренә кадәр журналга язылып калыгыз!

**Индексы – 83078**
**Сатып алырга теләүчеләр өчен телефон:**
**89172-37-26-42.**
**tilsimlikullar@mail.ru**




DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 999

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, Л.Н.Бәдретдинова, З.Ф.Фәсхиева
Битка салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты

Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Сул Болак ур., 44 й., 6 Б каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: (843) 292-22-91, 89053711571.
Электрон почта: tggpu-tat@yandex.ru. Сайт: ksu.ru

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.
Газета бушлай таратыла